ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
МУНИЦИПАЛЬНОГО
ОБРАЗОВАНИЯ
«НОВОЧЕРШИЛИНСКОЕ
СЕЛЬСКОЕ ПОСЕЛЕНИЕ»
ЛЕНИНОГОРСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
Заречная ул., дом 25,
поселок Новочершилинский,
Лениногорский район, 423274

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЛЕНИНОГОРСК
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
«ЯҢА ЧЫРШЫЛЫ
АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ»
МУНИЦИПАЛЬ
БЕРӘМЛЕГЕ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ
Заречная урамы, 25 нче йорт,
Яңа Чыршылы поселогы,
Лениногорск районы, 423274

Тел./факс: (8-85595) 3-04-32, Nchersh.Len@tatar.ru, leninogorsk.tatarstan.ru

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2019 елның 27 марты Яңа Чыршылы № 5

Лениногорск муниципаль районы
«Яңа Чыршылы авыл җирлеге»
муниципаль берәмлеге Башкарма
комитетының 2018 елның 27 июлендәге
11нче номерлы карары белән расланган
Адреслар бирү, үзгәртү һәм аннулировать
итү буенча Административ регламентка
үзгәрешләр кертү турында

Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2018 елның 21 декабрендәге «Россия Федерациясе Хөкүмәтенең кайбер актларына үзгәрешләр кертү һәм көчен югалткан дип тану турында»гы 1622нче номерлы карарына нигезендә, 2010 елның 27 июлендәге 210-ФЗ «Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүне оештыру турында»гы Федераль закон, Татарстан Министрлар Кабинетының 2010 елның 2 ноябрендәге «Татарстан Республикасы дәүләт хакимиятенең башкарма органнары тарафыннан дәүләт хезмәтләре күрсәтүнең административ регламентларын эшләү һәм раслау тәртибен раслау турында һәм Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының аерым карарларына үзгәрешләр кертү турында» 880нче номерлы карары нигезендә, Татарстан Республикасы Лениногорск муниципаль районы «Яңа Чыршылы авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Башкарма комитеты КАРАР БИРӘ:

1. Лениногорск муниципаль районы «Яңа Чыршылы авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Башкарма комитетының 2018 елның 27 июлендәге 11нче номерлы карары белән расланган Адреслар бирү, үзгәртү һәм аннулировать итү буенча Административ регламентка түбәндәге үзгәрешне кертергә:

1.5 пунктның 10нчы абзацында «бакчачылык, яшелчәчелек һәм коммерцияле булмаган дача оешмалары урнашу территорияләре» дигәнне «гражданнарның үз кирәкләре өчен бакчачылык яисә яшелчәчелек алып бару территориясе» сүзләренә алыштырырга.

2. Әлеге карарны Яңа Чыршылы авыл җирлеге территориясендә Яңа Чыршылы авылы,Заречная, 25 (җирле үзидарә бинасы), Центральная, 12 А адресы буенча урнашкан мәгълүмати стендларда һәм «Лениногорск муниципаль районы» муниципаль берәмлегенең рәсми сайтында «Авыл җирлекләре» бүлегендә һәм Татарстан Республикасының хокукый мәгълүмат рәсми порталында (pravo.tatarstan.ru) бастырып чыгарырга.

3. Әлеге карар үтәлешен контрольдә тотуны үз артымда калдырам.

“Яңа Чыршылы авыл җирлеге”
муниципаль берәмлеге башлыгы
вазифаларын башкаручы Р.А. Мөхәмәтшина